Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы
Сөйки авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

2019 елнын 28 нче феврале № 105

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге Советының 2014 елның 18 нче мартындагы 100 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге Советының муниципаль хезмәткәрләре һәм аларның вазыйфаи хәлләренә яисә аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләк алу, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, гамәлгә ашыру (сатып алу) һәм аны гамәлгә ашырудан кергән акчаларны кабул итүне хәбәр итү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының муниципаль вазыйфаларын биләүче затлар һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи хәлләренә яисә алар тарафыннан хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле бүләк алу, бүләк тапшыру һәм бәяләү, гамәлгә ашыру (сатып алу) һәм аны гамәлгә ашырудан кергән акчаларны күчерү турындагы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге Советының 2014 елның 18 нче мартындагы 100 нче номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының муниципаль вазыйфаларын биләүче затлар һәм Сөйки авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи хәлләренә яисә алар тарафыннан хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләк алу, бүләк тапшыру һәм бәяләү, аны гамәлгә ашыру (сатып алу) һәм аны гамәлгә ашырудан кергән акчаларны кабул итү турында хәбәр итү тәртибе” нигезләмәсенә үзгәреш кертергә:

1) Нигезләмәнең 2 пунктындагы икенче абзацында «хәлиткеч тавыш хокукы белән» сүзләрен " хәлиткеч тавыш хокукы белән даими (штат) нигездә , комиссиядә эшләүче " сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Сөйки авылы , Кызыл Армия урамы, авыл үзәге;

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Сөйки авылы , Колхоз урамы , библиотека бинасы; шулай ук мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы рәсми сайтында урнаштырырга

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районыСөйки авыл җирлеге
башлыгы, Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Сөйки авыл җирлеге Советы Рәисе В.П. Никитин